# КАРАР

## Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлеге составына керүче Бигеш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**№ 2**

**20.12.2021**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 20 нче декабрендә булып узган гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә сорау буенча беркетмә төзелде: «Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар, һәм ялгыз өлкәннәрдән кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлегенең Бигеш авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2022 елда үзара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотуга ризамы сез:

- торак пункт эчендәге юлга асфальт салу Садовая урамы һәм Гагарин урамы буенча бер өлеше.»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыены исемлегенә гражданнар җыенында сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар катнашучы 230 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 119 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 107 җыенда катнашучы тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен 12 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлегенең **Бигеш** торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре-дөрес.

2. «Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар, һәм ялгыз өлкәннәрдән кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Бигеш авыл җирлегенең Бигеш авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2022 елда үзара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотуга ризамы сез:

- торак пункт эчендәге юлга асфальт салу Садовая урамы һәм Гагарин урамы буенча бер өлеше» - соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

| | | |
|---|---|---|
| Бигеш авыл җирлеге башлыгы | ______________ (имза) | И.Р. Вәлиев (имза расшифровкасы) |